КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 декабрь г.Казань № 1226

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе мәсьәләләре» 2007 ел, 7 ноябрь, 614 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе мәсьәләләре» 2007 ел, 7 ноябрь, 614 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 9 июнь, 453 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 13 май, 379 нчы; 2011 ел, 9 август, 645 нче; 2012 ел, 29 ноябрь, 1045 нче; 2013 ел, 12 март, 158 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 812 нче; 2014 ел, 26 ноябрь, 918 нче; 2015 ел, 23 июнь, 457 нче; 2015 ел, 21 октябрь, 790 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 423 нче; 2016 ел, 13 август, 558 нче; 2017 ел, 1 март, 123 нче; 2017 ел, 5 август, 556 нчы; 2017 ел, 15 август, 571 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 742 нче; 2018 ел, 26 апрель, 286 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1296 нчы; 2020 ел, 21 август, 719 нчы; 2021 ел, 5 февраль, 59 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе хезмәткәрләренең чик санын вазыйфаи эш хаклары буенча хезмәт өчен түләүнең 303,442 мең сум күләмендәге айлык фонды белән 14 кеше итеп расларга.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе турындагы нигезләмәдә:

3.3 пунктта:

3.3.15 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.22 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.22. Беренчел яки торгызылган граждан хәле акты язуының булмавы турында хәбәрнамәләр бирүне гамәлгә ашыра, алар гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алу фактын билгеләү турында судка мөрәҗәгать итү өчен нигез булып тора.».

2. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин